| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.10.2024 г.Казань № 283/2-пр

2024 елда «Иң яхшы комбайнчы»
республика конкурсын уздыру
турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 18 сентябрендәге 2038-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә 2024 елгы уңышны урып-җыю эшләрен вакытында һәм сыйфатлы башкару, комбайнчыларны һөнәри камилләштерүгә өстәмә кызыксындыру булдыру, комбайнчы һөнәренең абруен һәм иҗтимагый әһәмиятен арттыру максатларында, б о е р а м:

1. 2024 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсын уздыру турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2023 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсын уздыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 10 ноябрендәге 411/2-пр номерлы боерыгын үз көчен югалткан, дип танырга.

3. Әлеге Боерык имзаланган көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Л.Н. Гариповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары - министр М.А. Җәббаров

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
2024 елның 15.10
283/2-пр номерлы боерыгы
белән расланды

2024 елда «Иң яхшы комбайнчы»
республика конкурсын уздыру турында
нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2024 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсын уздыру турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) 2024 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсын уздыруның максатын, аны оештыру һәм уздыру тәртибен билгели.

1.2. 2024 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсын (алга таба – конкурс) уздыруның максаты - Татарстан Республикасы территориясендә урып-җыю кампаниясе барышында ашлык суктыру, терлек азыгы әзерләү һәм чаптыру мәйданы буенча югары күрсәткечләргә ирешкән аеруча актив комбайнчыларны, механизаторларны бүләкләү.

1.3. Конкурсны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) оештыра.

1.4. Конкурсны уздыру сроклары, шартлары турында мәгълүмат Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (https://agro.tatarstan.ru) «Белгечләр өчен мәгълүмат» бүлегендә (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) әлеге Боерык үз көченә кергән көннән өч календарь көн эчендә урнаштырыла.

1.5. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 18 сентябрендәге 2038-р номерлы күрсәтмәсе белән каралган акчалар исәбенә Министрлык тарафыннан башкарыла.

1.6. Конкурсны уздыру эше түбәндәге принципларга нигезләнә:

гавамилек һәм ачыклык;

конкурста катнашучыларның тигезлеге.

## 2. Конкурста катнашу тәртибе

2.1. Конкурста катнашуга Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы эшчәнлеген алып баручы теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвешендәге оешмаларда, крестьян (фермер) хуҗалыкларында, шәхси эшкуарларда (алга таба – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) ашлык җыю комбайннарында, азык җыю комбайннарында, үзйөрешле чапкычларда һәм теземгә салу ургычларында эшләүче комбайнчылар, механизаторлар (алга таба - хезмәткәрләр) кертеләләр.

2.2. Конкурста катнашу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре үз

эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районындагы тиешле Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба - Идарә) 2024 елның 25 ноябренә кадәр түбәндәгеләрне тапшыралар:

хезмәткәр паспортының күчермәсен;

хезмәткәр белән төзелгән хезмәт шартнамәсенең йә хезмәткәр белән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе арасында хезмәт мөнәсәбәтләрен раслый торган башка документның күчермәсен;

Нигезләмәгә 1нче кушымтадагы форма буенча - ашлык суктыруга йә азык әзерләүгә, йә экипаж белән чаптыру мәйданнарына үткәрелгән мониторинг хисабын;

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча хезмәткәрнең үтәлмәгән бурычы булмавын раслый торган салым органы белешмәсен;

Нигезләмәгә 3нче кушымтадагы форма буенча - хезмәткәрнең үзе турында шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгы;

Нигезләмәгә 4нче кушымтадагы форма буенча - хезмәткәрнең тарату өчен рөхсәт ителгән үзе турында шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгы.

2.3. Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре җаваплы.

2.4. Хезмәткәрләр түбәндәге очракларда конкурста катнашуга кертелми:

Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән документларны Идарәгә Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы беренче абзацында билгеләнгән сроктан соңрак тапшырганда;

Нигезләмәнең 2.2 пунктында билгеләнгән документларны тапшырмаганда йә тулысынча тапшырмаганда;

тапшырылган документларда тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган белешмәләр булганда.

2.5. Тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча Идарә беркетмә төзи, анда хезмәткәрне конкурста катнашуга кертү йә кертүдән баш тарту турында мәгълүмат бирелә (алга таба – гаризаларны карау буенча беркетмә).

2.6. Идарә 2024 елның 4 декабренә кадәр Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

гаризаларны карау беркетмәсен;

Нигезләмәгә 1нче кушымтадагы форма буенча - ашлык суктыруга, азык әзерләүгә һәм экипаж белән чаптыру мәйданнарына үткәрелгән мониторинг хисапларының җыелма реестрын;

Нигезләмәнең 2.2 пункты нигезендә тапшырылган шәхси белешмәләрне эшкәртүгә хезмәткәрләрнең ризалыгын (3нче кушымта);

Нигезләмәнең 2.2 пункты нигезендә тапшырылган тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә хезмәткәрләрнең ризалыгын (4нче кушымта).

2.7. Министрлык Идарә тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә ашлык суктыру, азык әзерләү һәм чаптыру мәйданын анализлый, шулай ук аларны сортларга аера һәм түбәндәге күрсәткечләр буенча рейтинг төзи:

ашлык җыю комбайннары төркеме буенча – Татарстан Республикасында иң күп суктырылган бөртекле, кузаклы культуралар күләме буенча, Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә комбайннарның дүрт төркеме буенча;

азык җыю комбайннары төркеме буенча – Татарстан Республикасында иң күп әзерләнгән сенаж һәм силос күләме буенча, Нигезләмәгә 2нче кушымта нигезендә комбайннарның өч төркеме буенча;

үзйөрешле чапкычлар һәм теземгә салучы ургычлар төркеме буенча – Нигезләмәнең 2нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасында иң күп чаптырылган бөртекле, кузаклы һәм техник культуралар мәйданнары буенча.

## 3. Конкурсны уздыру тәртибе

3.1. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү өчен конкурс комиссиясе (алга таба - комиссия) төзелә, ул Нигезләмәнең 2.6 пункты нигезендә кергән документларны карый.

3.2. Комиссия составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына комиссиянең рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзалары керә. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия.

3.3. Комиссия рәисе комиссия утырышының көн тәртибен раслый, комиссия утырышын уздыру урынын һәм вакытын билгели, комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә, комиссия утырышын уздыра. Комиссия секретаре комиссия әгъзаларына комиссия утырышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә, комиссия утырышларына материаллар әзерли, комиссия утырышларының беркетмәләрен төзи.

3.4. Комиссия эше утырышлар рәвешендә башкарыла. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, комиссия утырышы вәкаләтле булып санала. Карарлар комиссия утырышында катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

3.5. Комиссия карарлары комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Комиссия утырышы беркетмәсе комиссия утырышы узган көннән өч эш көне эчендә рәсмиләштерелә.

3.6. Комиссия утырышлары 2024 елның 10 декабреннән дә соңга калмыйча уздырыла.

3.7. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

республика башкарма хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан комиссия эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

бирелгән мәгълүматның дөреслеген тикшерергә;

үз утырышларына республика башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары вәкилләрен, оешмалар җитәкчеләрен комиссия компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен чакырырга.

3.8. Комиссия конкурста 490 кешене җиңүчеләр итеп билгели һәм гомуми күләме 20,0 млн. сум булган премияне алар арасында түбәндәгечә бүлә:

ашлык җыю комбайннары төркеме буенча конкурста бер җиңүчегә 50,0 мең сум күләмендә 190 премия - Татарстан Республикасында иң күп суктырылган бөртекле, кузаклы культуралар күләме буенча;

азык җыю комбайннары төркеме буенча конкурста бер җиңүчегә 50,0 мең сум күләмендә 50 премия - Татарстан Республикасында иң күп әзерләнгән сенаж һәм силос күләме буенча;

үзйөрешле чапкычлар һәм теземгә салучы ургычлар төркеме буенча конкурста бер җиңүчегә 40,0 мең сум күләмендә 50 премия - Татарстан Республикасында иң күп чаптырылган бөртекле, кузаклы һәм техник культуралар мәйданнары буенча.

Конкурста бер җиңүчегә (әлеге пунктның икенче, өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән конкурста җиңүчеләрдән тыш) 30,0 мең сум күләмендә 200 премия - Татарстан Республикасы буенча бөртекле һәм кузаклы культураларның гомуми урып-җыю мәйданында муниципаль районның чагыштырма күләмен исәпкә алып, Татарстан Республикасы муниципаль районнары арасында бүленә һәм Нигезләмәнең 2.6 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләр буенча, Татарстан Республикасында иң күп суктырылган бөртекле, кузаклы культуралар күләме буенча бәяләнә.

Премияләр күләме физик зат керемenә алына торган салым суммасы исәпкә алынмаган килеш күрсәтелә.

3.9. Конкурс йомгаклары комиссия утырышы беркетмәсе имзаланган көннән өч эш көне эчендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

3.10. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү Министрлык тарафыннан, 2024 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, премияләрне Нигезләмәнең 3.8 пункты нигезендә идарәләрнең исәп-хисап счетларына күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла, соңгылары аларны конкурста җиңүчеләрнең шәхси счетларына күчерәләр.

2024 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсын уздыру турында нигезләмәгә
1нче кушымта

**2024 елгы уңышны урып-җыюда иң яхшы комбайнчылар турында мәгълүмат (бөртекле һәм кузаклы культуралар)**

| ТР муниципаль районы | Хуҗалык | | Комбайн-ның төркеме | Комбайн-ның маркасы | Комбайн-ның чыккан елы | Комбайн-ның дәүләт № | Суктыру-да эшләгән көннәр саны | Урып-җыю башланганнан алып үсә бару тәртибендә соңгы нәтиҗәгә кадәр | | шул исәптән бер көндә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | суктырыл-ган, тонна | суктырыл-ган, гектар | суктырыл-ган, тонна | суктырыл-ган, гектар |
| | | | 1 төркем | | | | | | | | |
| | | | 2 төркем | | | | | | | | |
| | | | 3 төркем | | | | | | | | |
| | | | 4 төркем | | | | | | | | |

**2024 елда азык әзерләүдә иң яхшы комбайнчылар турында мәгълүмат**

| ТР муниципаль районы | Хуҗалык | Комбайн-чының Ф.И.Ат.ис. (атасының исеме - булса) | Комбайн-ның төркеме | Комбайн-ның маркасы | Комбайн-ның чыккан елы | Комбайн-ның дәүләт № | Суктыру-да эшләгән көннәр саны | Урып-җыю башланганнан алып үсә бару тәртибендә соңгы нәтиҗәгә кадәр | | шул исәптән бер көндә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | әзерләнгән, тонна | җыелган, гектар | әзерләнгән, тонна | җыелган, гектар |
| | | | 1 төркем | | | | | | | | |
| | | | 2 төркем | | | | | | | | |
| | | | 3 төркем | | | | | | | | |

**2024 елгы уңышны чаптыруда иң яхшы механизаторлар турында мәгълүмат**

| ТР муниципаль районы | Хуҗалык | Комбайн-чының Ф.И.Ат.ис. (атасының исеме - булса) | Агрегатның маркасы | Чапкыч-ның чыккан елы | Чапкыч-ның дәү-ләт № | Чапкычта эшләгән көннәр саны | Урып-җыю башланганнан алып үсә бару тәртибендә соңгы нәтиҗәгә кадәр | шул исәптән бер көндә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | бөртеклеләр, га | бөртеклеләр, га |
| | | | | | | | | |

2024 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсын уздыру турында нигезләмәгә
2нче кушымта

## 2024 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсында катнашу өчен ашлык җыю комбайннарын төркемнәргә бүлү

| Комбайн-ның классы | Комбайннарның маркасы | Двигательнең куәте, ат көче | Җитеште-рүчәнлек, га/смена | Үткәрү сәләте, кг/сек |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Енисей-1200 | 140 | 12 | 7,1 |
| | СК-5 «Нива» | 145 | 12 | 5,7 |
| | Вектор-410 | 209 | 16 | 7,7 |
| | Вектор-420 | 209 | 16 | 7,8 |
| | Массей Фергюссон-5650 | 180 | 15 | 7 |
| | Нова-320 | 180 | 14 | 6,2 |
| | КЗС-7 | 210 | 20 | 7,8 |
| | КЗС-812 | 230 | 22 | 7,8 |
| 2 | ДОН-1500 | 230 | 20 | 9,5 |
| | ДОН-1200 | 220 | 20 | 9 |
| | Лида-1300 | 250 | 25 | 9 |
| | Акрос-530 | 250 | 26 | 12 |
| | Акрос-550 | 280 | 27 | 12 |
| | КЗР-10 «Полесье» | 290 | 22 | 10,9 |
| | КЗС-10К | 250 | 22 | 10 |
| | Кейс-2366 | 239 | 22 | 13 |
| | Клаас МЕГА-204 | 245 | 22 | 8,2 |
| | Клаас МЕГА-208 | 260 | 24 | 8,2 |
| | Нью Холланд ТС-56 | 240 | 22 | 7,6 |
| | Нью Холланд ТХ-65 | 280 | 26 | 9 |
| | Сампо-3065 L | 260 | 17 | 10 |
| | Нью Холланд ТХ-68 | 290 | 22 | 10 |
| | Класс Доминатор-370 | 205 | 20 | 8 |
| | Клаас Мега-360 | 245 | 25 | 8,2 |
| | Клаас Мега-370 | 260 | 26 | 8,2 |
| | Джон Дир W 540 | 255 | 24 | 8 |
| | Джон Дир 9640 | 275 | 26 | 12,5 |
| | Челленджер СН 647 С | 276 | 25 | 10 |
| 3 | Акрос-580 | 300 | 28 | 12 |
| | Акрос-585 | 300 | 28 | 12 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Акрос-595 | 325 | 34 | 15 |
| | КЗС-1218 (GS 12) | 326 | 30 | 12,8 |
| | Сампо Комия С12 | 300 | 30 | 8 |
| | Нью Холланд CX 840 | 300 | 30 | 8 |
| | Нью Холланд CSX | 300 | 30 | 7,6 |
| | Нью Холланд CX | 326 | 30 | 8,6 |
| | Нью Холланд CS | 300 | 27 | 7,6 |
| | Клаас Трион - 530 | 299 | 30 | 8 |
| | Клаас Тукано - 430 | 300 | 30 | 8,2 |
| | Клаас Тукано - 450 | 300 | 30 | 8,2 |
| | Клаас Тукано - 470 | 326 | 32 | 15 |
| | Клаас Тукано - 480 | 326 | 32 | 15 |
| | Клаас Лексион - 480 | 312 | 36 | 15,8 |
| | Клаас Лексион - 540 | 312 | 36 | 15,8 |
| | Джон Дир-9560 | 305 | 28 | 9,5 |
| | Джон Дир-9660 | 338 | 28 | 9,5 |
| | Джон Дир-9670 | 300 | 30 | 10 |
| | Джон Дир-9750 | 310 | 30 | 12 |
| | Массей Фергюссон-7347 | 306 | 24 | 11 |
| 4 | РСМ-161 | 360 | 34 | 12 |
| | Клаас Тукано-570 | 378 | 34 | 12 |
| | Клаас Тукано-580 | 378 | 34 | 12 |
| | Челленджер 654В | 378 | 34 | 12 |
| | Торум-740 | 420 | 36 | 14 |
| | Торум-750 | 425 | 38 | 15 |
| | Торум-785 | 510 | 44 | 17 |
| | Клаас Трион - 730 | 408 | 40 | 13,2 |
| | Клаас Лексион - 550 | 351 | 25 | 12 |
| | Клаас Лексион - 560 | 400 | 40 | 13 |
| | Клаас Лексион - 570 | 400 | 40 | 13 |
| | Клаас Лексион - 580 | 400 | 40 | 13 |
| | Клаас Лексион - 650 | 419 | 42 | 15 |
| | Клаас Лексион - 670 | 419 | 42 | 15 |
| | Клаас Лексион - 740 | 523 | 48 | 16 |
| | Клаас Лексион - 770 | 523 | 48 | 19,5 |
| | Полесье GS3219 | 390 | 35 | 12 |
| | Полесье GS16 | 530 | 48 | 16 |

2024 елгы урып-җыю эшләрендә катнашкан азык җыю комбайннары төркеме

| Комбайн-ның классы | Комбайннарның маркасы | Двигательнең куәте, ат көче | Җитештерүчәнлек, т/сәг |
|---|---|---|---|
| 1 | К-Г-6 "Полесье" | 250-280 | 90 |
| | КСК 600 | 240 | 108 |
| | Дон 680 | 290 | 110 |
| 2 | КВК 800 | 450 | 130 |
| | РСМ 1401 | 495 | 140 |
| | Ягуар 810 | 299 | 115 |
| | Ягуар 830-840 | 321-407 | 120-130 |
| | Ягуар 850-870 | 398-438 | 132-140 |
| | Джон-Дир | 450-460 | 132-138 |
| 3 | РСМ F2650 | 643 | 200 |
| | Ягуар 970-980 | 775-884 | 230-250 |
| | Нью-Холланд | 578-824 | 160-220 |
| | Кроне | 650-980 | 150-300 |

2024 елгы урып-җыю эшләрендә катнашкан үзйөрешле чапкычлар төркеме

| Комбайн-ның классы | Чапкычларның маркасы | Двигательнең куәте, ат көче | Җитештерүчәнлек, га/сәг |
|---|---|---|---|
| 1 | МакДон | 150 | 7 |
| | Челленджер | 120 | 5 |
| | Джон Дир | 110 | 6 |
| | Кейс | 120 | 6 |
| | Нью Холланд | 120 | 6 |
| | Массей Фергюссон | 85 | 5 |
| | ЕС-1 | 155 | 4,5 |
| | КСУ-1 | 157 | 4,5 |
| | Мещера Е-403 | 88 | 4 |
| | CS-200 | 200 | 7,6 |

2024 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсын уздыру турында нигезләмәгә
Знче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә
РИЗАЛЫК

Мин,__________________________________________________________________________,

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса))

Шәхесне таныклый торган документ______________ _____________(документ төре)
сериясе________ № _________,
___________________________________________________________________________
бирелгән (кайда, кем тарафыннан һәм кайчан)

Теркәлү адресы :_____________________________________________________________
____________________________________________________________________________,
Фактта яшәү адресы:__________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык), ИНН 1654019555, Министрлыкның юридик адресы: 420014, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Федосеев ур., 36 йорт;

Татарстан Республикасының
__________________________________________________________муниципаль районындагы
(муниципаль район исеме)
____________________________________________________________________________

Министрлыкның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба - Идарә),
ИНН_____________, Идарәнең юридик адресы:
____________________________________________________________________
2024 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсында катнашу максатларында үземнең шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси белешмәләр исемлеге: шәхеснең паспортындагы (шәхесне таныклаучы документтагы) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), туу датасы, паспорт белешмәләре (шәхесне таныклаучы башка документ белешмәләре), шәхси белешмәләр, яшәү урыны адресы, эш урыны, элемтә өчен телефон (өй, кәрәзле, эш), салым түләүченең идентификация номеры, шулай ук хезмәт шартнамәсендәге (хезмәт мөнәсәбәтләрен раслый торган документтагы) башка шәхси белешмәләр, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә

түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау хакында салым органы белешмәсе.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси белешмәләр белән гамәлләр кылу исемлеге: автоматлаштыру чараларын кулланып яисә андый чараларны кулланмыйча, башкарыла торган теләсә нинди гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) җыелмасы: шәхси белешмәләрне җыю, яздыру, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), аерып алу, куллану, тапшыру (тарату, бирү, файдалану), шәхесне ачыклау мөмкинлеген бетерү (обезличивание), блокировкалау, төшереп калдыру, юкка чыгару.

Әлеге ризалык имзаланган көненнән биш ел дәвамында гамәлдә була.

«Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре белән танышканымны, шәхси белешмәләрне яклау өлкәсендәге хокукларның һәм бурычларның миңа аңлатылуын раслыйм, әлеге ризалыкны Министрлык һәм (яисә) Идарә адресына язган гариза буенча теләсә кайсы вакытта кире алырга мөмкин булуын беләм.

Имза :______________________________

Дата: _____________________________

2024 елда “Иң яхшы комбайнчы” республика конкурсын уздыру турында нигезләмәгә
4нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

**Тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә**
**РИЗАЛЫК**

Мин,______________________________________________________________________________,

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

Шәхесне таныклый торган документ ______________________________(документ төре)
Документның сериясе, номеры: _________________бирелү датасы: __________________
_________________________________________________________________
Бирган орган:_______________________________________________________________
_________________________________________________________________________________,
Яшәү адресы:____________________________________________________________
_________________________________________________________________________________

«Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль Законның $10^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык), ИНН 1654019555, Министрлыкның юридик адресы: 420014, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Федосеев ур., 36 йорт; Татарстан Республикасының
_________________________________________________________муниципаль районындагы
(муниципаль район исеме)
_________________________________________________________________________________

Министрлыкның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба - Идарә),
ИНН____________, Идарәнең юридик адресы:
___________________________________________________________________

(алга таба - бергә “оператор” дип атала) 2024 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсында катнашу максатларында үземнең шәхси белешмәләрне таратуга (тапшыруга, бирүгә, файдалануга) ризалык бирәм.

## 1. Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси белешмәләр ИСЕМЛЕГЕ

| № т/с | Шәхси белешмәләр | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | ӘЙЕ | ЮК |
| 1. | Фамилиясе | | |
| 2. | Исеме | | |
| 3. | Атасы исеме (булса) | | |
| 4. | Туган елы, ае, көне һәм урыны | | |
| 5. | Адресы | | |
| 6. | Белеме | | |
| 7. | Һөнәре | | |

## 2. Эшкәртү өчен шартлар һәм тыюлар билгеләнә торган шәхси белешмәләр категорияләре һәм исемлеге

| № т/с | Шәхси белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. [Шәхси белешмәләр категориясе] | | |
| | [Шәхси белешмәләр исемлеге] | |

2. Әлеге ризалыкның 2 пункты шәхси белешмәләр субъекты теләге буенча шәхси белешмәләрне эшкәртүче оператор ягыннан чикләүләрсез тутырыла. Шартлар һәм тыюлар шәхси белешмәләрне чикләнмәгән яисә аерым бер даирәдәге затларга оператор тарафыннан тарату һәм (яисә) бирү гамәлләрен чикләүне яисә тыюны күздә тота.

3. Түбәндәге шартлар куела: алынган шәхси белешмәләр аларны эшкәртүче оператор тарафыннан аның белешмәләрдән бары тик аерым бер хезмәткәрләргенә файдалана алуны тәэмин итә торган эчке челтәре аша йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, йә алынган шәхси белешмәләрне тапшырмыйча гына таратылырга мөмкин (шәхси белешмәләр субъекты теләге буенча тутырыла).

_______________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________.

Операторның чикләнмәгән затлар даирәсенә файдалана алу мөмкинлеге бирелә торган мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр һәм шәхси белешмәләр субъектының шәхси белешмәләре белән башка гамәлләр түбәндәге сылтамада: https://agro.tatarstan.ru.

Әлеге ризалыкның гамәлдә булу срогы:

___________________________________________________________________________ .

(ризалыкның гамәлдә булуының төгәл срогын күрсәтергә)

Шәхси белешмәләр субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне тапшыру (тарату, бирү, файдалану) шәхси бюелешмәләр субъектының оператор адресына бирелгән язма таләбе буенча теләсә кайсы вакытта туктатылырга тиеш.

Имза:________________________________

Дата: ________________________________